Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 29 июле 57№

Әлки муниципаль районы Советының 2017 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының өченче затлар хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәтен (җир кишәрлекләреннән тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм оешмаларына файдалану өчен арендага бирү тәртибен раслау турында» 94 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы «Дәүләт яки муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендага ала торган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 159-ФЗ номерлы Федераль законның 3,5 статьяларына таянып, Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Советының 2017 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының өченче затлар хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәтен (җир кишәрлекләреннән тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм оешмаларына файдалану өчен арендага бирү тәртибен раслау турында» 94 номерлы карарына ( алга таба – Тәртип) (2019.12.04, 235№ редак.) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.7 пунктын өстәргә:

1.7. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалаучылар шулай ук «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы шәхси эшмәкәрләр булмаган физик затлар була ала.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин